КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 03 февраль г.Казань № 90

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан нәтиҗәле файдалану предметына капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешү төзү планлаштырыла торган инвестиция проектын бәяләү тәртибен раслау хакында» 2022 ел, 7 октябрь, 1084 нче карарына, преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр турында» 2022 елның 13 сентябрендәге 1602 номерлы карары, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвестиция проектын гамәлгә ашыру шартларын, аңа карата шундый килешү төзелгән, шул исәптән аны гамәлгә ашыру этаплары һәм капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүнең шартларын мониторинглауны гамәлгә ашыру тәртибен раслау хакында» 2022 ел, 07 октябрь, 1085 нче карары белән расланган «Инвестиция проектын гамәлгә ашыру шартларын, аңа карата шундый килешү төзелгән, шул исәптән аны гамәлгә ашыру этаплары һәм капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүнең шартларын мониторинглауны гамәлгә ашыру тәртибенщ (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә мондый килешү төзелгән инвестиция проектын, шул исәптән аны гамәлгә ашыру этапларын (алга таба - килешү шартларын

үтәү мониторингы нәтиҗәләре буенча белешмә) яклау һәм капиталлауларны бүләкләү турында килешү шартларын үтәүне мониторинглау нәтиҗәләре буенча белешмәләр нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан инвестиция проектларын, шул исәптән аларны гамәлгә ашыру этапларын, капиталлауларны һәм гамәлгә ашыру шартларын яклау һәм бүләкләү турында килешүләр шартларының үтәлеше турында хисап әзерләү (алга таба - килешүләр шартларының үтәлеше турында хисап).»;

7 пунктның беренче абзацында «күрсәткечләрен» сүзен «мәгълүматын» сүзенә алмаштырырга, «мониторинг нәтиҗәләре буенча белешмә әзерли» сүзләрен «килешү шартларын үтәүне мониторинглау нәтиҗәләре буенча белешмә әзерли» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы ел саен, 1 марттан да соңга калмыйча, вәкаләтле органнан әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә алынган килешү шартларының үтәлешен мониторинглау нәтиҗәләре буенча белешмәләр нигезендә:

а) әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада каралган форма буенча килешүләр шартларының үтәлеше турында хисап төзи һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына җибәрә;

б) әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә инвестиция проекты этабын гамәлгә ашыру турында хисап төзи (күрсәтелгән хисапны формалаштырган елдан алдагы елда һәр Килешүгә карата инвестиция проектының чираттагы этабын гамәлгә ашыру срогы килеп җиткщн) һәм аны капиталлауларны яклау һәм бүләкләү турындагы килешүләр реестрында чагылдыру өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына җибәрә. Күрсәтелгән хисап «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 18 өлеше нигезендә төзелә.»;

9 пунктның беренче абзацында «мониторинг нәтиҗәләре буенча җыелма хисапны» сүзләрен «килешүләр шартларының үтәлеше турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 2 нче кушымтада:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әлеге белешмә әзерләнде ____________________________________________

(вәкаләтле органның тулы исеме, ИНН,

______________________________________________________________________

ОГРН, адрес)

______________________________________________________________________

(алга таба - вәкаләтле орган) әлеге килешү төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру шартларын, шул исәптән инвестиция проектын гамәлгә ашыру этапларын, 20_____ елның ____________________________ елның ___ 20___ елдан алып узган чорда капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турындагы килешүнең шартларын тикшерү нәтиҗәләре буенча һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:»;

1.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.4 пунктта «вәкаләтле оешма» сүзләрен «вәкаләтле орган» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 3 нче кушымта исемендә «Җыелма хисап» сүзләрен «Хисап» сүзенә алмаштырырга;

Тәртипкә 4 нче кушымта исемендә «Белешмә» сүзен «Хисап» сүзенә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ягыннан булган һәм Россия Федерациясенеке булмаган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турындагы килешүләрне төзү, үзгәртү, туктату кагыйдәләрен раслау турында» 2022 ел, 07 октябрь, 1086 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы ягыннан булган һәм Россия Федерациясенеке булмаган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турындагы килешүләрне төзү, үзгәртү, туктату кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның «б» пунктчасының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүчегә карата «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бөлгенлек (банкротлык) турындагы эш буенча эш кузгатылмаган.»;

5.6 пунктта «26» саннарын «25» саннарына алмаштырырга;

5.7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Әлеге Кагыйдәләрнең 5.3 пунктында билгеләнгән срокта вәкаләтле орган бәйләнешле шартнамәләр турында өстәмә килешү проектын карый һәм карау йомгаклары буенча:»;

6.6 пунктта «килешүгә өстәмә килешү төзүнең мөмкин булмавы турында» сүзләрен «Килешүләр төзү кагыйдәләренә 45 нче кушымта нигезендә форма буенча төзелгән килешүгә өстәмә килешү төзүдән баш тарту турында» сүзләренә алмаштырырга;

6.7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.7. Әлеге Кагыйдәләрнең 6.3 пунктында билгеләнгән срокта вәкаләтле орган өстәмә килешү проектын карый һәм карау йомгаклары буенча:»;

6.13 пунктның дүртенче абзацында «49» саннарын «50» саннарына алмаштырырга;

8.7 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин